**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы № 113 «18 » 10. 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 27 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү буенча Нигезләмәгә 2.10 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«б) мөрәҗәгатьне карау өчен башка дәүләт органнарындагы, җирле үзидарә органнарындагы һәм башка вазыйфаи затлардагы документларны һәм материалларны, судлардан, алдан тикшерү органнарыннан тыш, соратып алалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.А.Такиулин